Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
Сухрау авыл җирлегенә керә торган Смыловка авылының гражданнар җыелышы нәтиҗәләре турында

КАРАР

2025 ел 12 нче ноябрь № 1

Рәсәй Федерациясенең 2025 нче елның 20 нче мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм дәүләт хакимияте системасы эчендәге урыннарда үзидарәне оештыруның гомуми нигезләре турында» федераль законының 45нче, 69 нчы маддәләре һәм Татарстан Республикасының 2004 елның 28 нче июлендәге № 45-ЗРТ «Татарстан Республикасында урыннарда үзидарә турында» законының 35 нче маддәсе нигезендә Сухрау авылында 2025 нче елның 12 нче ноябрендә «Түбәндә күрсәтелгән кешеләрдән тыш Татарстан Республикасың Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлегенә керә торган Смыловка авылы җирлегендә даими яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан 2026 нчы елда 1000 сум зурлыгында үзбилгеләнеш түләвен кертүгә ризамы?» дигән сорау буенча гражданнар җыелышы уздырылды. Түбәндәге кешеләрдән түләү алынмый: I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучы ирләрнең тол калучы хатыннарыннан; көндезге бүлектә укучы студентлардан; Рәсәй Федерациясе Кораллы көчләренә өлешчә мобилизация нигезендә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, ир-атлар һәм хатын-кызларыннан; II төркем инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсия алучылар сумманың 50% ын түли. Төбәк әһәмиятендәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне юнәлтергә:

– традицион күмелеш урыннарын ремонтлау, чикләр кору, җирләрен яхшырту;

– елга асты суларының табигый чыгыш урыннарын (чишмәләрне) яхшырту.

«ӘЙЕ» «ЮК»варианты сайлана.

Гражданнар җыелышының протоколы буенча:

Сайлау хокукына ия булган җыелыш катнашучылары исемлегенә 138 кеше кертелгән, җыелышта катнашкан һәм тавыш биргән кешеләр саны – 88 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән: «Әйе» өчен – 88 кеше, «Юк» өчен – 0 кеше.

Югарыдагы нигезгә таянып, гражданнар җыелышы карар итә:

1. Смыловка авылында (Сухрау авыл җирлеге, Түбән Кама муниципаль районы, Татарстан Республикасы) үткәрелгән гражданнар җыелышы узган дип һәм җыелыш нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча кабул ителгән карарны расларга: Смыловка авылы җирлегендә (Сухрау авыл җирлеге, Түбән Кама муниципаль районы Татарстан Республикасы) даими яшәп теркәлгән һәр ирешкән яшьтәге

гражданнардан 2026 нчы елда Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге Смыловка авылы биләмәсендә даими яшәп килү урыны буенча теркәлгән һәр 18 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк гражданнан 1000 сумлык үзбилгеләнеш түләвен кертүгә ризалыкны танырга. Түбәндәге кешеләрдән түләү алынмый: I төркем инвалидлардан; Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан; Бөек Ватан сугышы катнашучыларының тол хатыннарыннан; көндезге бүлектә укучы студентлардан; Рәсәй Федерациясе Кораллы көчләренә өлешчә мобилизация нигезендә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, ир-атлар һәм хатын-кызларыннан. II төркем инвалидлардан һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар күрсәтелгән сумманың 50% ын гына түли. Төбәк әһәмиятендәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне юнәлтергә:

– традицион күмелеш урыннарын ремонтлау, чикләр кору, җирләрен яхшырту;

– елга асты суларының табигый чыгыш урыннарын (чишмәләрне) яхшырту.

Карар: «ӘЙЕ» «ЮК» — кабул ителде.

3. Гражданнар җыелышы нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат такталарында һәм Сухрау авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән җәмгыятькә игълан итәргә.

4. Бу карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив-хокуки актлары реестрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыелышын җитәкләүче,
Сухрау авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Галимов